БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» 07 2023 ел № 189

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турындагы» 2023 елның 31 мартындагы 128 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2023 елның 31 мартындагы 128 номерлы «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турындагы» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче пунктны 3 нче пункт дип санарга;

1.2. 3 нче пунктны 4 нче пункт дип санарга;

1.3. 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен кабул иткәнчегә кадәр, торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында гражданнарны аз керемлеләр дип тану өчен җаваплы вазыйфаи затларга(хезмәткәрләргә), һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турындагы» 2023 елның 31 мартындагы 128 номерлы карары белән билгеләнгән чик күрсәткечләрен кулланырга.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов